МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от 19.10.2018 № 532

Казань ш.

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының “Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында” 2012 елның 27 июлендәге 127 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының “Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында” 2012 елның 27 июлендәге 127 номерлы (2013 елның 24 июнендәге 112 номерлы, 2014 елның 23 июнендәге 196 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларын урнаштыруга җаваплы зат итеп мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат бүлегенең төп киңәшчесен билгеләргә.”;

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибендә:

IV. бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“IV. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү Тәртибе

17. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып Министрлыкның рәсми басылып чыккан норматив хокукый актлары һәм “Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составында Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) яки Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен бердәм региональ интернет-порталы (алга таба – бердәм төбәк интернет-порталы) белән билгеләнгән аларга коррупциягә каршы экспертиза үткәрү һәм иҗтимагый фикер алышу максатларында билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) аларга коррупциягә каршы экспертиза үткәрү һәм иҗтимагый фикер алышу өчен урнаштырылган норматив хокукый актлар проектлары, Министрлык тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актлар проектлары санала.»;

18. Дәүләт сере булып саналучы мәгълүматлар яки конфиденциаль характердагы мәгълүматлар кергән Министрлыкның норматив хокукый актларына, Министрлык тарафыннан эшләнелә торган норматив хокукый актлар проектларына карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрелми.

19. Министрлык тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнар проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен норматив хокукый акт проектын Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнарына, башка органнарга һәм оешмаларга килештерүгә җибәрергә тиешле көн белән туры килә торган эш көне дәвамында норматив хокукый акт проектын эшләгән структур бүлекчә җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) аны, Министрлыкның рәсми сайтына һәм бердәм региональ порталга урнаштыру өчен, Министрлык тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен урнаштыруга җаваплы затка (алга таба – норматив хокукый актлар проектларын урнаштыруга җаваплы зат) җибәрә.

20. Норматив хокукый актлар проектларын урнаштыруга җаваплы зат норматив хокукый акт проектын эшләгән структур бүлек җитәкчесеннән (аның вазыйфаларын башкаручы заттан) норматив хокукый акт проектын алу көненә туры килә торган эш көне дәвамында аны Министрлыкның рәсми порталына һәм бердәм региональ порталга урнаштыра.

21. Министрлыкның норматив хокук актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен норматив хокукый акт проектын эшләгән структур бүлекчә җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) норматив

хокукый актлар проектларын урнаштыруга җаваплы затка юридик бүлеккә карау өчен җибәргән көнгә туры килә торган эш көне дәвамында җибәрә.

22. Норматив хокукый актлар проектларын урнаштыруга җаваплы зат норматив хокукый акт проектын эшләгән структур бүлек җитәкчесеннән (аның вазыйфаларын башкаручы заттан) норматив хокукый акт проектын алу көненә туры килә торган эш көне дәвамында аны Министрлыкның рәсми порталына һәм бердәм региональ порталга урнаштыра.

23. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен норматив хокук актлары проектларын урнаштырганда норматив хокукый акт проектын эшләүче - структур бүлекчә бәяләмәләрен җибәрү өчен адресын (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр кабул итә башлау һәм кабул итеп бетерү көнен күрсәтә.

24. Норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен урнаштыруның вакыты мондый урнаштыру көненнән соң кимендә биш көннән дә артык була алмый.

25. Норматив хокукый акт проекты коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү максатларында урнаштырылган вакыт эчендә кергән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буена бәяләмәләр кергән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмый бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында теркәлә.

26. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим итү характерында була, һәм норматив хокукый акт (норматив хокукый акт проектын) эшләүче - структур бүлекчә тарафыннан аны теркәгән көннән соң 15 көн эчендә мәҗбүри рәвештә карап тикшерелергә тиеш, әлеге Тәртипнең 27 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш.

Карап тикшерү нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка нигезле җавап җибәрелә (бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторлар турында мәгълүмат булмаган яки ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш), анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре исәбе һәм (яки) норматив хокукый актта яки норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциоген фактор белән килешмәү сәбәпләре чагылыш таба.

27. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәге бәяләмәләр карап тикшерелми:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан норматив хокукый актларга яки норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча эксперт сыйфатында аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар әзерләгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы раслаган формага туры килми торган.

28. 27 пунктның өченче абзацында күрсәтелгән очракта норматив хокукый акт (норматив хокукый акт проектын) эшләүче - структур бүлекчә мондый бәяләмәләрне, сәбәбен күрсәтеп, теркәүгә алган көннән соң 15 көннән дә соңга калмый кире кайтара.

29. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнар проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү йомгаклары буенча бәяләмәләрне карау нәтиҗәләре буенча норматив хокукый акт проектын эшләгән структур бүлек аны йә коррупциягә каршы бәйсез экспертиза вакытында ачыкланган коррупциячел факторларны юкка чыгарып эшләп бетерә, йә, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертә.

30. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпләү бу Тәртипнең 26 – 28 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

31. Норматив хокукый акт проектын эшләгән структур бүлекчә коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырылганнан соң норматив хокукый актка үзгәрешләр кертсә, норматив хокукый акт проекты яңадан коррупциягә каршы бәйсез экспертиза узарга тиеш.».

Министр Л.Р. Сафин